ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 Олы Кайбыч ав. № 480

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруны оештыру турында» 2021 елның 15 февралендәге 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның түләүсез кайнар ризык белән туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның кайнар ризык белән туклануының уртача кыйммәтен раслау турында» 2021 елның 06 сентябрендәге 826 номерлы, «2022 елга айлык акчалата һәм түләүләрнең башка төрләре турында» 2021 елның 07 сентябрендәге 842 номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын туклandыруны оештыру турында» 2021 елның 15 февралендәге 64 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2пунктта:

2.4. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның бер көнгә бер укучыга 55 (илле биш) сум 55 тиен суммага түләүсез кайнар ризык белән туклануын тәэмин итәргә.»;

2.5. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны 8 сум 30 тиен күләмендә субсидиядән һәм ата-ана (законлы вәкил) түләвеннән торган суммага ашатуны оештырырга.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча

«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров